МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

15.02.2016_ г. Казань № _под-208/16

**Татарстан республикасы мәгариф һәм фән министрлыгында дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерү ихтималы булган шәхси кызыксынуның килеп чыгуы турында хәбәр итү тәртибен раслау турында**

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы аедераль закон, «Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерү ихтималы булган шәхси кызыксынуның килеп чыгуы турында хәбәр итү тәртибе һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 22 декабрендәге 650 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерү ихтималы булган шәхси кызыксынуның килеп чыгуы турында хәбәр итү тәртибен (алга таба - Тәртип) расларга (кушымта итеп бирелә).

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Кадрлар сәясәте бүлегенә (Т.А.Иванова, Р.Ф.Гайфетдинова) түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы аппаратындагы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен, шулай ук хезмәт контрактлары төзегәндә гражданнарны бу боерык белән таныштырырга;

бу Тәртипне Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының мәгълүмат стендында урнаштырырга

4. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Мәгълүмат технологияләрен үстерү һәм куркынычсызлык бүлегенә (А.А.Кравцов) бу Боерыкны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең Рәсми порталындагы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының рәсми сайтында «Коррупциягә каршы көрәш» бүлегендә урнаштырырга.

7. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
министр
Э.Н.ФӘТТАХОВ

Татарстан Республикасы Мәгариф
һәм фән министрлыгының 2016 елның
15 февралендәге под-208/16 номерлы
боерыгы белән расланды

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫНДА ДӘҮЛӘТ ГРАЖДАН ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ ТАРАФЫННАН ВАЗЫЙФАИ БУРЫЧЛАРЫН ҮТӘГӘНДӘ МӘНФӘГАТЬЛӘР КАРШЫЛЫГЫНА КИТЕРӘ ТОРГАН ЯКИ КИТЕРҮ ИХТИМАЛЫ БУЛГАН ШӘХСИ КЫЗЫКСЫНУНЫҢ КИЛЕП ЧЫГУЫ ТУРЫНДА ХӘБӘР ИТҮ ТӘРТИБЕ**

1. Бу Тәртип Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында, үзләренә карата эшкә алучы вәкиле Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры булып торган (алга таба - министр) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре (алга таба – Министрлык, граждан хезмәткәрләре) тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерү ихтималы булган шәхси кызыксынуның килеп чыгуы турында хәбәр итү процедурасын җайга сала.

2. Вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерә алу ихтималы булган шәхси кызыксынуның килеп чыгуы турында хәбәр граждан хезмәткәре тарафыннан бу Тәртипкә кушымтада китерелгән формада язма хәбәр (алга таба - язма хәбәр) рәвешендә тутырылып, министрга җибәрелә.

3. Министр өч эш көне эчендә язма хәбәрне, башлангыч төстә карап тикшерү өчен, коррупция һәм башка хокук бозуларны кисәтү буенча эш өчен җаваплы затка (алга таба – җаваплы зат) җибәрә.

4. Язма хәбәрне башлангыч төстә карап тикшерү барышында җаваплы зат язма хәбәрне җибәргән граждан хезмәткәреннән анда бәян ителгән хәлләр буенча аңлатмалар алырга, дәүләт хакимияте органнарына, башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм мәнфәгатьле оешмаларга билгеләнгән тәртиптә запрослар җибәрүне тәкъдим итәргә хокуклы.

5. Язма хәбәрне башлангыч төстә карап тикшерү нәтиҗәләре буенча җаваплы зат нигезле бәяләмә әзерли. Башлангыч карап тикшерү барышында алынган язма хәбәр, бәяләмә һәм башка материаллар, җаваплы зат тарафыннан язма хәбәр кабул итеп алынганнан соң җиде эш көне эчендә, җаваплы зат тарафыннан Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе (алга таба – Комиссия) рәисенә җибәрелә.

6. Бу Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән запрослар җибәрелгән очракта, язма хәбәр, бәяләмә һәм башка материаллар җаваплы зат тарафыннан тиешле Комиссия рәисенә язма хәбәр алынганнан соң 45 көн эчендә тапшырыла. Әлеге вакыт Комиссия рәисе тарафыннан озайтылырга мөмкин, әмма 30 көннән арта алмый.

7. Комиссия язма хәбәрне, бәяләмә һәм башка материаллар Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссия турында нигезләмәгә туры китереп, карап тикшерә.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерү ихтималы булган шәхси кызыксынуның килеп чыгуы турында хәбәр итү тәртибенә кушымта

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры Э.Н.Фәттаховка

______________________________дән
(вазыйфа атамасы)

_________________________________

_________________________________

_________________________________
(Ф.И.О. адрес, телефон номеры)

Вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китергән яки китерә алу ихтималы булган шәхси кызыксынуның барлыкка килүе турында
ЯЗМА ХӘБӘР

Вазыйфаи бурычларымны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерү ихтималы булган (кирәклесенең астына сызарга) шәхси кызыксынуымның барлыкка килүе турында хәбәр итәм.

Шәхси кызыксынуымның килеп чыгуына нигез булып торучы шартлар: ___________________________________________________________
________________________________________________________________________________

Үтәлешенә шәхси кызыксынуым йогынты ясый торган яки йогынты ясау ихтималы булган вазыйфаи бурычлар: ________________________________________________________
________________________________________________________________________________

Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яки җайга салу буенча тәкъдим ителә торган чаралар: ____________________________________________________________________
________________________________________________________________________________

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе утырышында шәхсән катнашырга ниятлим/ниятләмим (кирәклесенең астына сызарга).

__________ ______________ ______________________________
(дата) (имза) (тулы имза)